КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 21 ноябрь г.Казань № 1248

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Invest in Tatarstan» имидж кампаниясен тормышка ашыруга бәйле оешмаларның чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 21 июль, 637 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 13 август, 814 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Invest in Tatarstan» имидж кампаниясен тормышка ашыруга бәйле оешмаларның чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

8 пунктта:

беренче абзацта «30 көн эчендә» сүзләрен «биш көн эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «30 нчы календарь көннән иртәрәк» сүзләрен «бишенче календарь көннән иртәрәк» сүзләренә алмаштырырга, «(2022 елда заявкаларны кабул итү тәмамлану срогы сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 календарь көнгә кадәр кыскартылырга мөмкин)» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларның конгресс-күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү, конкурсларны оештыру-техник яктан тәэмин итү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 23 август, 768 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 18 март, 247 нче һәм 2022 ел, 13 август, 814 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Юридик затларның конгресс-күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү, конкурсларны оештыру-техник яктан тәэмин итү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

8 пунктның икенче абзацында «30 нчы календарь көннән иртәрәк» сүзләрен «бишенче календарь көннән иртәрәк» сүзләренә алмаштырырга, «(2022 елда заявкаларны кабул итү тәмамлану срогы сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 календарь көнгә кадәр кыскартылырга мөмкин)» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы<br>
Премьер-министры А.В.Песошин